# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

## Татарстан ССР Президенты вазыйфаларына керешү турында

1 маддә. Татарстан ССР Конституциясе нигезендә сайланган Татарстан ССР Президенты Татарстан ССР Президенты сайлауларын үткәргәннән соң бер айдан да соңга калмыйча үз вазыйфаларына керешә.

2 маддә. Татарстан ССР Президенты үз вазыйфаларына керешкәндә Татарстан ССР Конституциясе нигезендә ант итә.

3 маддә. Ант итү мизгеленнән Татарстан ССР Президенты үз вазыйфаларына керешкән һәм Татарстан ССР халык депутаты һәм республика халык депутатларының җирле Советлары вәкаләтләрен тапшырган дип исәпләнә.

4 маддә. Татарстан ССР Президенты вазыйфаларына керешкән мизгелдән ун көннән дә соңга калмыйча Татарстан ССР Министрлар кабинеты яңа сайланган Татарстан ССР Президенты каршында үз вәкаләтләреннән ваз кичә. Татарстан ССР Конституциясе нигезендә Татарстан ССР Министрлар кабинетының яңа составы төзелгәнчегә кадәр Министрлар кабинеты үз вазыйфаларын башкаруны дәвам итә.

5 маддә. Татарстан ССР Президенты, Татарстан ССР вице-президенты, Президент Советы һәм Татарстан ССР Президенты каршындагы башка консультатив органнарның, шулай ук Татарстан ССР Президенты аппараты эшчәнлеге Татарстан ССР республика бюджеты исәбенә финанслана. Татарстан ССР Президентының һәм Татарстан ССР вице-президен-

тының эшчәнлеген тәэмин итү мәсьәләләре Татарстан ССР Югары Советы Президиумы актлары нигезендә көйләнә.

6 маддә. Татарстан ССР Президентының хезмәт хакы Татарстан ССР Югары Советы тарафыннан билгеләнә.

7 маддә. Татарстан ССР Президентында Татарстан ССР туграсы төшерелгән һәм "Татарстан Совет Социалистик Республикасы Президенты" дип язылган түгәрәк мөһер була.

8 маддә. Татарстан ССР Президентының, Татарстан ССР вице-президентының һәм аларның гаиләләренең иминлеге махсус хезмәт белән тәэмин ителә.

9 маддә. Татарстан ССР Президентының тору урыны - Татарстан ССРның башкаласы, Казан шәһәре.

Татарстан ССР Президенты рәсми булган урыннарда Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт әләме күтәрелә.

10 маддә. Әлеге Закон кабул итү мизгеленнән үз көченә керә.

Татарстан ССР Югары Советы
Рәисенең беренче урынбасары Р.Шәмгунов

Казан шәһәре,
1991 елның 4 июле
№ 1141-XII